


## УМК «Туган телдә сөйләшәбез»

## Без язны яратабыз

### Шигырьне әйтеп бетер!

Елгада бозлар кузгалды,
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап атлады
Ямьле һәм күңелле ... ( яз.)

### Уен “Торыйк- торыйк, торналар”

Барлык балалар аркалары белән түгәрәк ясап, урындыкларга утыралар. Уртада алып баручы. Барысы бергә кабатлыйлар:

Торыйк- торыйк, торналар
Торкылдашып торалар.
Торганнары очып китә,
Тормаганны тоталар.

Әйтеп бетерүгә, алып баручы кулларын чәбәкли, балалар урындыкларыннан сикереп торалар. Алып баручы торып өлгермәгән баланың аркасына кагылып ала һәм ул бала алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.

### Җырлы-хәрәкәтле уен “Яз һәм балалар”

Балалар: Исәнме, яз, матур яз
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Яшел чуклар элдеңме?
Яз: Саумы, нәни дусларым!
Сезне сагынып килдем мин.
Сезгә аяз көннәр дә,
Яңгыр да китердем мин.
Балалар: Яңгыр яу, яу, яу
Бар табигать юынсын,
Тирә- як көлеп торсын.



Яңгыр: Яу, яу дип яңгыр телисез,
Ә үзегез качып йөрисез.

***Тизәйткеч:*** Жы- жы- жы- жы, яз килде, жылы!

### Эндәш ятлау “Кояш, чык!”

Кояш, чык, чык, чык!
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка Казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык- сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.